Киләчәге булган көллият !

Сәламәтлек – кеше тормышында иң мөһим кыйммәтләрнең берсе.Без тормышыбызны медицина хезмәткәрләреннән башка күз алдына да китерә алмыйбыз. 50 елдан артык Түбән Кама медицина көллияте медицина хезмәткәрләрен әзерли.Аларда Һөнәрләренә карата кешелеклелек, шәфкатьлелек, игътибарлылык кебек сыйфатлар тәрбияли.

Түбән Кама медицина көллияте тарихы 1966 елның 1 июленнән башлана.Түбән Камада 155 нче № МЗ РТ приказы буенча сәнәгать базасында медицина училищесы ачыла.

Медицина көллияте ачылуына нигез салучы үзәк район шифаханәсенен баш табибы Матросов Леонид Сергей улы булып тора.

Беренче уку елына өч бүлеккә (фельдшер,акушер,шәкать туташы) 90 укучы кабул ителде.Шәһәребез медицина хезмәткәрләренә мохтаҗ иде.

Бугенге көндә Дәүләт Автоном һөнәри белем бирүче “Түбән Кама медицина көллияте”ГОСТ ISO 9001-2011 (ISO 9001^2008) 20011 елдан менеджмент системасы сыйфатына туры килүче сертификатына ия булып тора.

”100 лучших в России” дигэн Бөтенроссия конкурсы дипломанты,2012 ел.,”Ведущие учреждения здравоохранения России” Милли Реестр катнашучысы, 2015 ел.,”Лучшие товары и Республики Татарстан” республика конкурсы лауреаты, 2019 ел.,”Подготовка медицинских, фармацевтических работников и лиц ОВЗ для лечебно – профилактических учреждений”халыкка хезмәт күрсәтү номинациясендә.
Уку йорты тарихына карап алыйк...Түбән Кама медицина коллиятенең беренче директоры итеп Уразова Роза Гайсә кызы билгеләнә.Ул яхшы оештыручы,алдынгы укыту һәм тәрбияләү методларын әйдәп баручы .Роза Гайсә кызы хәтерләрдә үз эшен намус белән башкаручы табиб һәм җитәкче булып саклана.

Медицина училищесының мөһим бурычларның берсе, ул квалификацияле кадрлар әзерләү.Ул вакытта республикада алар җитешеп бетми иде.Ә укырга керү җиңелләрдән түгел иде.Бер урынга – 5 кеше.

Укытучылар – барлыгы дүрт кеше ,Поликарпова Зинаида Максим кызы ( рус теле һәм әдәбияты укытучысы) Бабушкина Зинаида Алексей кызы (химия һәм биология укытучысы), Уразова Роза Гайсә кызы (физиология укытучысы),Гайнуллина Вәсимә Зиннәт кызы ( тарих укытучысы).
Белгечләрне әзерләүдә гамәли эшчәнлекне алып баручы ТАССР ның атказнган табибы Михеева Антонина Никифор кызы,Курмаева Лия Абдулла

кызы – табиб  дермато-венеролог,Зиганшин Әзһәр Әгъләм улы – Үзәк хастаханәсенең баш табиб урынбасары .Простнева Маргарита Ефим кызы-педиатр.Гамәли укыту базасы булып үзәк район хастаханәсенең бүлекләре торды.

1978 елның февралендә медицина училищесының директоры итеп Соколов Владимир Александр улы билгеләнде.Белгечлеге буенча ул педиатр, Биектау район хастаханәсендә   хезмәт куйган. Владимир Александр улы бик кешелекле җитәкче булган.Хезмәткәрләрнен барысына ярдәмгә килгән, тормыш хәлләрен белешеп, кайгыртып торганы өчен коллектив аңа бик рәхмәтле.Шулай ук ул медицина училищесының яңа бинасын булдыру да күп көчен куйган кеше.

1997 елдан башлап ул Түбән Кама шәһәренең сәламәтлек саклау һәм исәпкә алу бүлегендә мөдир булып хезмәт куйган.   1997 елның декабереннән медицина көллияте белән Нуретдинов Ринат Кыям ул җитәкчелек итә. Түбән Камада онкологияне ачыклау,дәвалау,операцияләр ясау һәм химия терапияләр үткәрүнең беренче адымнарын аның исеме белән бәйле.Урта медицина хезмәткәрләренең эш үзенчәлекләре белән таныш булуы, кадрларны әзерләүдә Ринат Кыямрвич мөһим  урын алып тора.Ул зур уңышларга ирешә һәм дәрәҗәле исемнәргә лаек була:Рәсәй Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган табибы.Хуҗалык эшләрен оештыру,укыту-тәрбия эшләрен камилләштерүдә тирән фикерләү,искиткеч эш сөюе белән аерылып тора.Аның җитәкчелегендә уку йорты күп профильле һәм күп функцияле булды.Материаль,техник базасы үсте, тәҗрибәле укытучылар составы ныгыды.

Нәкъ менә Нуретдинов  Ринат Кыям улына Медицина көллияте нигезендә “Медицинский массаж”  күзләре күрмәү сәбәпле сәламәтлекләре чикле булган гражданнар өчен белгечлеген ачарга тәкъдим ителде.Инклюзив белем алу мөмкинлеге бу категория гражданнары очен, Татарстан Республикасында бердән бер уку йорты.

Үзенең укытучылары  һәм укытучы табиблары белән генә түгел, ә үзенең төрле шәһәр һәм республика ярышларында җиңүче студентлары белән дә тиешле дәрәҗәдә горурлана ала.Менә безнең волонтерларны һәрвакыт түземсезлек белән  инвалидлар, ветераннар,ятим балалар, инвалид балалар , CJVID 19 карантины вакытында Түбән Кама шәһәренең өлкән кешеләре түземсезлек белән көтеп тордылар.Бүгенге көндә шәһәребезнең күп урта һөнәри белем бирүче уку йортлары абитуриентларных җитмәве белән кытлык кичерә, ләкин безнең медиөина көллиятенә йөзләгән гариза кабул ителә.

Абитуриентларны көллияткә укырга керү нияте,авыру кешеләргә ярдәм итәргә теләү, аларның авыртуларын җиңеләйтү теләге китерә.Һәм бу бик сөендерә.Чөнки нәкъ менә шундый егет һәм кызлардан үз һөнәрләренең чын осталары чыга да.